**Лубян авыл җирлеге башлыгы**

**Карар**

«07» апрель 2023 ел № 6

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы «Лубян авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә эштән чыгарылган терекөмешле лампалар туплау урынын (урыннарын) булдыру, кулланучыларга аның (аларның) урнашу урыны турында мәгълүмат бирү хакында

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы, «Энергияне сак тоту һәм энергетик нәтиҗәлелекне арттыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 23 ноябрендәге 261-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Тиешенчә булмаган җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин яктырту җайланмалары, электр лампалары өлешендә җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 28 декабрендәге 2314 номерлы карары нигезендә Кукмара муниципаль районы Лубян авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Лубян авыл җирлеге территориясендә эштән чыгарылган терекөмешле лампалар туплау урынын билгеләргә: Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Лубян авылы, Мәктәп урамы, 7 йорт.

2. Күп фатирлы йортларның милекчеләре, яллаучылары, кулланучылары булган терекөмешле лампалар кулланучыларның эштән чыгарылган терекөмешле лампаларын туплау урыннары Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 28 декабрендәге 2314 номерлы карары белән расланган Тиешенчә булмаган җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин яктырту җайланмалары, электр лампалары өлешендә җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләренең 4 пункты нигезендә билгеләнә.

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән эштән чыгарылган терекөмешле лампаларны туплау урыннары, әлеге күп фатирлы йортларда туплау урыннарын оештыру өчен биналар булмау сәбәпле, эштән чыгарылган терекөмешле лампаларны туплау урыннарын оештыру мөмкин булмаган

очракта, шул исәптән күп фатирлы йортларның милекчеләре, яллаучылары, кулланучылары булган терекөмешле лампаларны кулланучылар өчен дә билгеләнгән дип билгеләргә.

4. Кулланучыларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Туембаш авыл җирлеге территориясендә эштән чыгарылган терекөмешле лампалар туплау урынының (урыннарының) урнашкан җире турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында,Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Лубян авыл җирлеге җирле үзидарә органнары биналарында мәгълүмати стендларда (стойкаларда) урнаштыру юлы белән хәбәр итәргә.

5. Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырып, халыкка игълан итәргә; шулай ук «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Лубян авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенә калдырырга.

Лубян авыл җирлеге башлыгы Г.Ф.Тежикова